ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Фәррахов Айрат Зәки улы белән берлектә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.

2. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын рәсми бәяләмә алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәсми бәяләмәсен алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында карaганда Татарстан Республикасы Дәүләт

Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты  Фәррахов Айрат Зәки улын билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2193-VI ДС